Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

10 ноябрь, 2025 ел № 3

Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлегенең Черемыш авылы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җыенны билгеләү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге уставының 23 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Ленино-Кокушкино авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 109 номерлы (2021 елның 14 декабрендәге 34 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Гражданнарга үзара салым кертү һәм аннан файдалану мәсьәләсе буенча Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлегенең Черемыш авылында җыен билгеләргә.

Гражданнар җыенын 2025 елның 24 ноябрендә 14.00 сәгатьтә Гурин урамындагы иске чиркәү янында уздырырга.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2026 елда Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Черемыш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 5000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларын, махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Гурин ур.)

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Ленино-Кокушкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгы А.Р. Сәйфетдинов